| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

05.06.2019 г. Казань № 66

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 7 апрелендәге 26 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Министрлар Кабинетының 2019 елның 15 маендагы 395 нче «Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы 2010 елның 18 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы» типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында»гы карары басылып чыгуга бәйле рәвештә,

**БОЕРАМ :**

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2016 елның 7 апрелендәге 26 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе карамагындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2017 елның 25 октябрендәге 115 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.1 пункттагы дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

"җәмгыятьтә коррупциягә каршы көрәш формалаштыру.»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12.Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин.».

Башлык В.А. Кудряшов